**РАСЛЫЙМ**
Татарстан Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессының
Милли Шура рәисе

______________

**В.Г. Шәйхразыев**

# “Сез иң гүзәл кеше икәнсез”
## *конкурсы нигезләмәсе*

Бөтендөнья татар конгрессының
“Сез иң гүзәл кеше икәнсез” конкурсын уздыру турында

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. **Гомуми нигезләмәләр**
1.1. “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” конкурсының (алга таба Конкурс) оештыручысы – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты (алга таба Конгресс);
1.2. Конкурс турында Нигезләмә конгресснның рәсми сайтында (https://congress.tatar/) “Рәсми басма” сәхифәсендә урнаштырыла.
1.3. Конкурста иң яхшы эшләргә ( төрле яшь категориясендә) I, II, III нче урыннар бирелә һәм дипломнар, бүләкләр тапшырыла;
1.4. Жюри игътибарга лаек өстәмә хезмәтләрне сайлап алып, аларга Рәхмәт хатлары тапшырырга да хокуклы;
1.5. Барлык катнашучыларга да дипломнар бирү каралмаган;
1.6. Конкурска бер генә хезмәт килсә/яисә бер хезмәт тә килмәсә, Конкурс үткәрелмәде дип таныла.
2. **Конкурсның максаты һәм бурычлары:**
2.1. Конкурсның максаты – укытучының җәмгыятьтәге ролен, дәрәҗәсен үстерү, балаларда әлеге һөнәр ияләренә хөрмәт тәрбияләү;
2.2. Конкурс Укытучылар көне уңаеннан оештырыла;
2.3. Балаларга укытучы һөнәренең ни дәрәҗәдә әһәмиятле, шул ук вакытта катлаулы һәм мөһим икәнлеген күрсәтү;

2.4. Укытучылар арасында үз һөнәренең фанаты булган, гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган шәхесләрне барлау, аларны халыкка таныту;
2.5. Бөтендөнья татар конгрессы сайтын һәм социаль челтәрләрдәге төркемнәрен популярлаштыру.

3. **Конкурсның номинацияләре:**

3.1. Конкурс "Минем яраткан укытучым" номинациясе буенча уза.
3.2. Конкурс төрле яшь категорияләрендә уза: **10 – 15** яшькәчә, **16 – 20** яшькәчә, **21 яшьтән** өлкәнрәкләр;
3.3. Конкурс **ВКонтакте** социаль челтәрендәге Бөтендөнья татар конгрессы (https://vk.com/club235577801) конкурслары төркемендә уза.

4. **Конкурста катнашучылар:**

4.1 Конкурста **10 яшьтән өлкәнрәк** булган һәркем катнаша ала;
4.2 Конкурста катнашучы **Вконтакте** төркеменә яраткан укытучысының фотосын урнаштыра (берничә фото да рөхсәт ителә) һәм шунда аның эшчәнлеге, ни өчен нәкъ менә шул мөгаллимне яратуы турында тәфсилләп яза.
4.3. Катнашучы Конгрессның Вконтакте**дагы** Бөтендөнья татар конгрессы конкурслары төркеменә язылырга тиеш;
4.4. Катнашучы язма башында ук үзенең исем-фамилиясен, яшен, кайдан булуын күрсәтергә тиеш.

5. **Конкурсны үткәрү шартлары һәм таләпләре:**

5.1. Конкурска **Вконтакте** төркемендә үз хезмәтләрен җибәрүчеләрнең язмалары эчтәлекле, аңлаешлы итеп язылырга тиеш.
5.2. Катнашучы үзе турында тулы мәгълүмат куя. Исем-фамилиясе, яше һәм яшәү урыны билгеле булмаса, конкурска килгән эш төшеп кала;
5.3. Конкурска тәкъдим ителгән фотолар сыйфатлы булырга тиеш;
5.4. Конкурс эшләрен кабул итү срогы тәмамланганнан соң килгән эшләр каралмый;
5.7. Конкурска старт 2026 елның **11 нчы сентябрендә** бирелә. Ул **4 нче октябрьгә** кадәр дәвам итәчәк.
5.8. Конкурсның иң яхшы эшләрен ике номинация буенча да жюри сайлап ала. Аларның исемнәре Бөтендөнья татар конгрессы сайтында һәм конгрессның ВКонтакте төркемендә **12 нче октябрьдә** игълан ителәчәк. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасының көне һәм вакыты аерым хәбәр ителә.
5.9 Конкурска җибәрелгән эшләрне Конгрессның сайтына урнаштыру, "Татарлар – без бергә" газетасында язмаларны чыгару оештыручылар хокукында.